КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 апрель г.Казань № 401

2022 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә күрсәтелгән юридик зат милкендәге «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркы («Алабуга-2» индустриаль паркы) капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба оссия Федерациясе законнары нигезендә «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең устав капиталын арттырып, Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 8 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган юридик затлар милкендә булган капиталь төзелеш объектларына һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез милек объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыруга, алга таба мондый юридик затларның устав капиталларын Россия Федерациясе законнары нигезендә арттыру белән күрсәтелгән юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында карар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2019 ел, 23 апрель, 331 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2022 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте (алга таба - акционерлык җәмгыять) милкендәге 1 851 535,39194 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы тәкъдимен

акцияләрнең (өлешләрнең) 100 проценты Татарстан Республикасыныкы булган «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының акционер җәмгыять милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга («Алабуга-2» индустриаль паркы) һәм 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

субсидия бирү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

субсидия «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм «2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 - 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2017 - 2024 елларга Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын булдыру һәм үстерү» ярдәмче программасының «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона» индустриаль паркы инфраструктурасы объектларын («Алабуга-2» индустриаль паркы) төзү, модернизацияләү һәм (яисә) реконструкцияләү» чараларын гамәлгә ашыруга бюджет чараларын алучы буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Россия Федерациясе законнары нигезендә акционерлык җәмгыятьнең устав капиталын тиешле дәрәҗәдә арттыруга юнәлдерелгән акционерлык җәмгыятьнең гамәлләрен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 28 апрель, 401 нче
карарына 1 нче кушымта

## «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте милкендә булган, капитал салулар гамәлгә ашырыла торган капиталь төзелеш объектлары

| Т/с | Капиталь төзелеш объекты-ның исеме | Объект-ның куәте | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификациясе буенча егәрлекне үлчәү берәмлеге | Инвестицияләү юнәлеше | Заказчы исеме | Төзүче исеме | Файдалануга тапшыру срогы | Объектның смета кыйммәте, мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән) | | | | | | | | | | | Капитал салулар күләме, мең сум (өстәлгән кыйммәткә салым белән) | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | барысы | шул исәптән өстәлгән кыйммәткә салым | шул исәптән проект документациясен әзерләүгә, инженерлык тикшеренүләрен үткәрүгә бүлеп бирелә торган акча күләме | 2018 елга | 2019 елга | 2020 елга | 2021 елга | 2022 елга | 2023 елга | 2024 елга | 2025 елга | 2026 елга | барысы | 2018 елга | 2019 елга | 2020 елга | 2021 елга | 2022 елга | 2023 елга | 2024 елга | 2025 елга | 2026 елга |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
| 1. | «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 4.1.1 нче корпус» | 15 989,3 | кв.метр | Төзелеш/ реконструкция | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ | «Алабуга Девелопмент» ҖЧҖ | 2024 елның декабре | 2 201 569,64 | 366 928,27 | 76 800,0 | | | 341 246,15 | 322 945,14 | 1 022 000,0 | 314 000,0 | 201 378,35 | | | 4 096 000,0 | | | 341 246,15 | 322 945,14 | 1 022 000,0 | 314 000,0 | 2 095 808,71 | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | «Синергия» индустриаль-технологик паркының күпфункцияле комплексы. 5 нче, 6 нчы, 7 нче корпус» | 61 207,57 | кв.метр | Төзелеш | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ | «Алабуга Девелопмент» ҖЧҖ | 2023 елның июне | 17 538 397,16 | 2 923 066,0 | 268 172,52 | | | 414 968,03 | 1 094 000,0 | 2 410 000,0 | 2 410 000,0 | 2 700 000,0 | 2 700 000,0 | 5 809 429,13 | 14 483 000,0 | | | 414 968,03 | 1 094 000,0 | 2 410 000,0 | 2 410 000,0 | 2 700 000,0 | 2 700 000,0 | 2 754 031,97 |
| 3. | «Синергия» автокомпонентлар җитештерү буенча индустриаль-технологик парк. 3 нче корпус. ПАН-прекурсор җитештерү буенча заманча завод» | 21 160,14 | кв.метр | Төзелеш | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ | «Алабуга Девелопмент» ҖЧҖ | 2023 елның июне | 7 724 381,57 | 1 414 192,38 | 185 021,9 | 631 327,81 | 452 930,13 | 1 737 126,37 | 4 865 227,89 | 37 769,37 | | | | | 4 621 000,0 | 631 327,81 | 452 930,13 | 1 737 126,37 | 139 527,41 | 37 769,37 | 1 622 318,91 | | | |
| 4. | «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 8 нче корпус» | 85 415,64 | кв.метр | Төзелеш | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» АҖ | «Алабуга Девелопмент» ҖЧҖ | 2023 елның марты | 11 121 994,1 | 1 635 841,86 | 76 680,0 | | | | 541 451,26 | 5 157 479,19 | 640 000,0 | 4 783 063,65 | | | 8 926 000,0 | | | | 541 451,26 | 5 157 479,19 | 640 000,0 | 2 587 069,55 | | |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 28 апрель, 401 нче
карарна 2 нче кушымта

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона» акционерлык җәмгыяте милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия акчасын бүлү

| Т/с | Капиталь төзелеш объектының исеме | Субсидияләр суммасы, мең сум (өстәлгән кыйммәткә салымнан башка) |
| --- | --- | --- |
| 1. | «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 4.1.1 нче корпус» | 150 000,0 |
| 2. | «Синергия» индустриаль-технологик паркының күпфункцияле комплексы. 5 нче, 6 нчы, 7 нче корпус» | 920 060,91892 |
| 3. | «Синергия» автокомпонентлар җитештерү буенча индустриаль-технологик парк. 3 нче корпус. ПАН-прекурсор җитештерү буенча заманча завод» | 31 474,47302 |
| 4. | «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 8 нче корпус» | 750 000,0 |
| | Барлыгы | 1 851 535,39194 |

___